ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2024 г.Лениногорск № 1356

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гаиләләргә, гражданнарга һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 08 декабрендәге 1123 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында «2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы карарының 3 пункты нигезендә мобилизацияләнгән гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 08 декабрендәге 1123 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, хәрби бурычларны ирекле рәвештә башкаручы гражданнар арасыннан ярдәм чараларының кушымтада бирелә торган исемлеген расларга махсус хәрби операция барышында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, Махсус хәрби операция уздыру зонасына

командировкага җибәрелгән Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәләре, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) (алга таба - гаиләләр) һәм югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның махсус хәрби операция ветераннары (катнашучылары) гаиләләренә (гаилә әгъзаларына).»

2.Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 21 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.leninogorsk.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, вакытлы матбугат басмасында - «Лениногорские вести»газетасында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче М.Н.Гирфанов

Галимова Л.М.
5-44-72